**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 1 сентябрендәге 2784 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан**
**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге иҗтимагый советына**
**әгъзалыкка кандидатураларны карап тикшерү һәм**
**әгъзаларны раслау тәртибе**

Казан шәһәре Думасының 2025 елның 26 мартындагы 5-37 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге иҗтимагый советы турында»гы карары нигезендә, шулай ук халык һәм җирле үзидарә органнары арасында үзара хезмәттәшлекне көчәйтү, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүдә җәмәгать контроле һәм гражданнарның катнашу дәрәҗәсен арттыру максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге иҗтимагый советына әгъзалыкка кандидатураларны карап тикшерү һәм әгъзаларны раслау тәртибе турында нигезләмәне (1 номерлы кушымта) гамәлгә кертергә.

2. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге иҗтимагый советына әгъзалыкка кандидатураларны карап тикшерү буенча Казан шәһәре Башкарма комитеты комиссиясе составын (2 номерлы кушымта) расларга.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевка йөкләргә.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы –**
**беренче урынбасар** **А.Р.Нигъмәтҗанов**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 1 сентябрендәге
2784 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге иҗтимагый советына әгъзалыкка кандидатураларны карап тикшерү һәм әгъзаларны раслау тәртибе турында нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә Казан шәһәре Думасының 2025 елның 26 мартындагы 5-37 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге иҗтимагый советы турында»гы карарының (алга таба – Казан шәһәре Думасының «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге иҗтимагый советы турында»гы карары) 5 статьясындагы 2 өлеше нигезендә Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге иҗтимагый советына кандидатураларны карап тикшерү һәм составының өчтән бер өлешен раслау тәртибен билгели.

2. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге иҗтимагый советына (алга таба – Казан шәһәре иҗтимагый советы) әгъзалыкка кандидатлар буенча Казан шәһәре Башкарма комитетына кергән тәкъдимнәрне карап тикшерү өчен Казан шәһәре иҗтимагый советына әгъзалыкка кандидатураларны карап тикшерү буенча Казан шәһәре Башкарма комитеты комиссиясе (алга таба – Комиссия) төзелә.

3. Казан шәһәре иҗтимагый советына әгъзалыкка кандидатлар буенча Казан шәһәре Думасының «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге иҗтимагый советы турында»гы карарының 7 статьясындагы 3 өлешенең икенче абзацы, 4 өлеше нигезендә әзерләнгән, Казан шәһәре Башкарма комитетына кергән гаризалар һәм документлар, 1 эш көненнән дә соңга калмыйча, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратына (алга таба – Аппарат) теркәү өчен җибәрелә.

Гаризага әлеге Нигезләмәгә кушымтада каралган форма буенча кандидатның шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә язма ризалыгы теркәп бирелергә тиеш.

4. Тәкъдимнәр, теркәгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, карап тикшерү өчен Комиссиягә тапшырыла.

5. Комиссия утырышы Казан шәһәре иҗтимагый советы составына кертү турындагы гаризаларны кабул итү туктатылган көннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча үткәрелергә тиеш.

6. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының кимендә 2/3 өлеше катнашса, тулы хокуклы дип санала.

Утырышны Комиссия рәисе ача һәм алып бара.

7. Утырыш барышында Комиссия Казан шәһәре иҗтимагый советына әгъзалыкка кандидатуралар буенча тапшырылган документларга, шул исәптән алардагы белешмәләрнең дөрес булу-булмавы өлешендә, шул исәптән тиешле дәүләт органнарына һәм башка оешмаларга билгеләнгән тәртиптә мөрәҗәгатьләр җибәрү юлы белән бәя бирә.

Тапшырылган документлар Казан шәһәре Думасының «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге иҗтимагый советы турында»гы карарының 7 статьясында (Казан шәһәре иҗтимагый советының беренче составы формалашкан очракта – 6 статья) күрсәтелгән исемлеккә туры килмәгән, шулай ук тапшырылган белешмәләр дөрес булмаган очракта, Казан шәһәре иҗтимагый советына әгъзалыкка кандидатура кире кагыла.

8. Һәр кандидат буенча аерым тавыш бирү уздырыла, карар Комиссиянең барлык әгъзалары арасында гади күпчелек тавыш белән кабул ителә.

Казан шәһәре иҗтимагый советына әгъзалыкка кандидатлар буенча тавыш биргәндә, Комиссия әгъзалары тарафыннан кандидатларның төрле өлкәләрдә, шул исәптән кеше һәм гражданин хокукларын һәм ирекләрен яклау, хәйрия эшчәнлеге өлкәсендә Казан шәһәре алдындагы казанышлары исәпкә алына.

Тавыш бирү йомгаклары буенча, тавышлар саны тигез булу сәбәпле, кандидатлар саны биштән артып китсә, тигез санда иң аз тавыш җыйган кандидатлар буенча кабат тавыш бирү уздырыла.

9. Утырыш уздырылган көннән алып 3 эш көне эчендә беркетмә төзелә, ул Комиссия рәисе, Комиссия секретаре һәм Комиссиянең утырышта катнашучы барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

10. Беркетмә Аппарат тарафыннан Казан шәһәре иҗтимагый советы әгъзаларын раслау турында Казан шәһәре Башкарма комитеты карары проектын әзерләү өчен нигез булып тора.

Казан шәһәре Башкарма комитеты карары Комиссия утырышын уздырганнан соң 30 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә.

11. Казан шәһәре иҗтимагый советына әгъзалыкка кандидатура кире кагылган очракта, беркетмәдән өземтә, беркетмә төзелгән көннән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, әлеге кандидатны күрсәткән коммерциягә нигезләнмәгән оешмага җибәрелә.

---

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 1 сентябрендәге
2784 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге иҗтимагый советына әгъзалыкка кандидатураларны карап тикшерү буенча Казан шәһәре Башкарма комитеты комиссиясе**
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Алиев Булат Рафаил улы | комиссия рәисе, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе |
| Яковлев Виктор Иосифович | комиссия рәисе урынбасары, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе урынбасары – хокук идарәсе башлыгы |
| Бакулин Эдуард Михайлович | комиссия секретаре, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының оештыру идарәсе башлыгы |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Сәгыйтова Гүзәл Рәмзил кызы | Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары |
| Шәмсетдинов Ренат Хәррас улы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе башлыгы |
| Салихов Альберт Иршат улы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе башлыгы |
| Жаворонков Владимир Владимирович | Казан шәһәре Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе башлыгы |
| Фәтхетдинов Роман Рәмиз улы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Совет районы администрациясе башлыгы |
| Бочкова Ирина Андреевна | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе урынбасары – кадрлар сәясәте идарәсе башлыгы |

| | |
|---|---|
| Смирнова Ирина Петровна | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының социаль сәясәт идарәсе башлыгы |
| Ризванов Ирек Асаф улы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы |
| Абзалов Азат Искәндәр улы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе башлыгы |
| Заһидуллина Алия Рөстәм кызы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты рәисе |
| Гарипов Линар Зимфир улы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитеты рәисе |

___________________

Казан шәһәре Башкарма комитеты
тарафыннан Казан шәһәре
муниципаль берәмлеге
иҗтимагый советына әгъзалыкка
кандидатураларны карап тикшерү
һәм әгъзаларны раслау тәртибе
турында нигезләмәгә
кушымта

**Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык**

Мин, ________________________________________________________________,

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

түбәндәге адрес буенча яшәүче: ______________________________________________,

паспорт: сериясе ________ № ___________, _____________________________________

_________________________________________________________ тарафыннан бирелгән,

(кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)

әлеге ризалык белән Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Кремль урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратына шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә ризалык бирәм. Ризалык Казан шәһәре муниципаль берәмлеге иҗтимагый советына әгъзалыкка кандидатурамны карап тикшерү, шул исәптән, Казан шәһәре иҗтимагый советына әгъзалыкка кандидатурамны карап тикшергәндә, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле белешмәләрне өченче затларга тапшыру максатыннан бирелә.

Ризалык түбәндәге шәхси мәгълүматларга кагыла: ризалык бирүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), туган көне, ае, елы һәм урыны; гражданлыгы; башка дәүләт (дәүләтләр) гражданлыгы булу, яшәүгә рөхсәт яки Россия Федерациясе гражданинының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукынраслый торган документ турында мәгълүмат; гомумгражданлык паспорты турында мәгълүмат (сериясе, номеры, бирү датасы, паспорт биргән орган атамасы, бүлекчә коды); яшәү урыны буенча теркәлү адресы һәм фактта яшәү адресы; вазифасы, эш (хезмәт) урыны (оешманың тулы атамасын, шәхси эшмәкәрнең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы – булган очракта) күрсәтеп); белеме (белгечлеге, квалификациясе, белем бирү учреждениесе атамасы, уку йортын тәмамлау датасы); гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме; федераль дәүләт гражданлык хезмәтенең һәм (яки) Россия Федерациясе субъекты гражданлык хезмәтенең һәм (яки) муниципаль хезмәтнең һәм (яки) юстициянең һәм (яки) прокуратура хезмәткәренең класс чины, дипломатик рангы, хәрби һәм (яки) махсус званиесе (кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән); дәүләт, ведомство, төбәк бүләкләре һәм муниципаль бүләкләр (бүләкнең исеме, бүләкләү датасы); иҗтимагый өлкәдә эш тәҗрибәсе; алынмаган яки тулысынча үтәлмәгән суд хөкеме булу турында мәгълүмат; телефон (өй, эш, кәрәзле) номеры; электрон почта адресы (булган очракта).

Әлеге ризалык, минем тарафтан анкетада күрсәтелгән белешмәләрне җыюны, яздыруны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, аныклауны (яңартуны, үзгәртүне), алуны, файдалануны, тапшыруны (таратуны, бирүне, файдалану мөмкинлеген), шәхси үзенчәлекләрен юк итүне, тыюны, юкка чыгаруны, аларга карата тикшерү үткәрүне кертеп, автоматлаштыру чараларын кулланып яки мондый чараларны кулланмыйча, шәхси мәгълүматларыма карата гамәлләр (гамәлләр җыелмасын) башкару, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә шәхси мәгълүматларым белән теләсә нинди башка

гамәлләр башкару өчен бирелә.

Миңа түбәндәгеләр турында хәбәр ителде:

әлеге ризалык аны имзалаган көннән һәм чикләнмәгән вакыт дәвамында гамәлдә була;

шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык ирекле формада язылган гариза нигезендә кире алынырга мөмкин.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык кире алынган очракта, 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 6 статьясындагы 1 өлешенең 2-11 пунктларында күрсәтелгән нигезләр булганда, операторның шәхси мәгълүматларны эшкәртүне ризалыктан башка дәвам итәргә хокуклы булуын әлеге ризалык белән раслыйм.

_______________________________________________

(ризалык биргән затның фамилиясе һәм инициаллары)

____________________

(шәхси имза)

___________________

(дата)